СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЧЕПЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» сентябрь 2018 ел № 125

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Чепья авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Чепья авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2018 елның 18 сентябрендәге 124 номерлы Чепья авыл җирлеге Советы карары, «Чепья авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2018 елның 18 сентябрендәге 15 номерлы Чепья авыл җирлеге Башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2019 елда Чепья авыл җирлегендә яшәүче 18 яше тулган, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- Арбор авылында: зират коймаларын алыштыру, юл-урам челтәрен һәм асфальт-бетон түшәмәсен норматив хәлгә китерү;

- Сырья авылында: спорт мәйданчыгын сатып алу, Комсомол урамында урнаштыру һәм төзекләндерү, периметр буенча койма кору, чишмәләрне төзекләндерү;

- Иске Чепья авылында: юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү, балалар өчен уен мәйданчыгын сатып алу, аны Трудовая урамында урнаштыру һәм төзекләндерү, периметр буенча койма кору;

- Тагашур авылында: юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү, зиратта хуҗалык бинасын ремонтлау, балалар уен мәйданчыгын сатып алу, аны Совет урамында урнаштыру һәм төзекләндерү, периметр буенча койма кору;

- Мельничная авылында: Заречная урамындагы буаны тирәнәйтеп чистарту, зират коймасы кору, балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм аны Заречная урамында урнаштыру;

- Чепья авылында: юл-урам челтәрен һәм юлларга асфальт-бетон түшәмәсен норматив хәлгә китерү, Арборка елгасы аша күпер төзү, зират коймасын кору, чишмәләрне төзекләндерү, балалар уен һәм спорт мәйданчыкларын сатып алу, аны Ленин урамында урнаштыру һәм төзекләндерү, янгынга каршы 5 гидрант урнаштыру, янгынга каршы колонка һәм аларга комплектлау әйберләре сатып алу.

**ЮК ӘЙЕ".**

3. Чепья авыл җирлеге Советы карары нигезендә, аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җыелган акчаны экономияләү очрагында, экономияләнгән акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.

4. Әлеге карарны «Хезмәт» район газетасында һәм pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар аңа имза куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Чепья авыл җирлеге башлыгы А.Г. Нотфуллин